КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 2 апрель г.Казань № 339

Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларының аерылгысыз технологик өлеше булган корылмаларга караган мөлкәт исемлеген раслау турында

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең 19 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларының аерылгысыз технологик өлеше булган корылмаларга караган мөлкәт исемлеген расларга.

2. Бу карарның гамәле 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2026 ел, 2 апрель, 339 нчы карары белән расланды

Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларының аерылгысыз технологик өлеше булган корылмаларга караган мөлкәт исемлеге

| ТФГК коды* | Исеме | Искәрмә |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 220.41.20.20.711 | Электр тәэмин итү комплексы | Линия юл хезмәте территориясен, шулай ук төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларын яктырту өчен инженерлык коммуникацияләре: һава һәм кабель электр үткәргеч линияләре, электр бүлү пунктлары, трансформатор ярдәмче станцияләре, электр трансформаторлары, терәкләрне һәм яктырткычларны үз эченә алган электр белән тәэмин итү комплекслары |
| 220.42.11.10.120 | Автомобиль юллары, шул исәптән урам-юл челтәре, һәм башка автомобиль һәм җәяүлеләр юллары | Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юллары элементлары: җир катламы, юл өслеге, юл кырыйлары, текә ярлар, канаулар, су агызу лотоклары, яңгыр су агызгычлары, ерганаклар, дренаж, ныгыту корылмалары, ял мәйданчыклары һәм автомобиль астын карау өчен эстакадалары, терәү |
| 220.42.11.10.121 | Юл өслеге камилләштерелгән капиталь типтагы автомобиль юлы | |
| 220.42.11.10.129 | Башка төркемнәргә кертелмәгән автомобиль юллары, шул исәптән урам-юл челтәре, һәм | |

*ТФГК – Төп фондлар гомумроссия классификаторы.

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | башка автомобиль һәм җәяүлеләр юллары | стеналары һәм япмалары (беседкалары) булган автотранспорт куеп тору урыннары, күчү-тиз йөрү полосалары, транспорт чишелешләре белән кисешкән урыннарда башка юлга чыгу юллары, кисешкән һәм кушылган урыннар, тимер юл кичүләре, сигнал баганалары (тумбалар), эстакадалар (ныгыту корылмалары булган яки булмаган автомобиль юллары күперләренә һәм юл үткәргечләргә керү юллары), баскычлы төшү урыннары, автобус тукталышлары һәм автопавильоннар (кереп туктау урыннары һәм утырту мәйданчыклары белән), чистарту корылмалары, су үткәрү торбалары, терлек куу урыннары, тротуарлар, җәяүлеләр һәм велосипед юллары, юл билгеләре, светофорлар һәм башка урам хәрәкәтен җайга салу чаралары |
| 220.42.11.10.150 | Керү юллары, юл өстендәге һәм юл астындагы транспорт һәм җәяүлеләр өчен юл үткәргечләр, велосипед юллары | |
| 220.42.11.10.159 | Башка керү юллары, юл өстендәге һәм юл астындагы транспорт һәм җәяүлеләр өчен юл үткәргечләр, велосипед юллары | |
| 220.42.11.10.130 | Юл киртәләре | металл киртә |
| 220.42.13.10.110 | Коры җир транспортының барлык типлары һәм җәяүлеләр өчен теләсә нинди материаллардан ясалган күперләр һәм юл үткәргечләр | Күперләр һәм тоннельләр, тоннель тибындагы юл үткәргечләр һәм ныгыту корылмалары белән яки алардан башка җәяүлеләр өчен җир астыннан чыгу урыннары |
| 220.42.13.10.111 | Автомобиль юлы күпере | |
| 220.42.13.10.119 | Башка коры җир транспортының барлык типлары һәм җәяүлеләр өчен теләсә нинди материаллардан ясалган күперләр һәм юл үткәргечләр | |
| 220.42.13.10.120 | Автотранспорт чаралары хәрәкәте өчен җир өсте автомобиль юллары (автомобиль юлы эстакадалары) | |
| 220.42.13.10.130 | Тоннельләр | |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 220.42.21.13.123 | Канализация системасы | Төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлларының юл өчен бүлеп бирелгән полосасы чикләрендә урнашкан су чыгару һәм чистарту корылмалары һәм алардагы ясалма корылмалар, шулай ук линия юл хезмәтенең канализация челтәрләре, канализация һәм чистарту насос станцияләре, су чыгару һәм чистарту корылмалары |
| 220.42.21.13.127 | Агызып төшерелә торган суларны чистарту корылмалары | |
| 220.41.20.20.900 | Башка төркемнәргә кертелмәгән спорт-сәламәтләндерү корылмалары һәм башка корылмалар | Юл үткәргечләр (төбәк яки муниципальара әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлы, җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлы, гомуми файдаланудагы хосусый автомобиль юлы һәм тимер юллар аша яисә урам аша чыга торган ныгыту корылмалары булган яки булмаган күперле автомобиль юлы), виадуклар (тирән чокыр, упкын, коры үзән, чоңгыл аша чыга торган ныгыту корылмалары булган яки булмаган күперле автомобиль юлы), керү автомобиль юллары һәм линия юл хезмәтенең янгын сүндерү өчен сулыклары, акча түләү пункты |

______________________